Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

**2021 елның 29 октябре** **№ 65**

**«Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Кама Тамагы муниципаль районы _ структурасын раслау турында» 2003 елның 28 декабрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кама Тамагы муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшен камилләштерү максатларында, «2014-2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы чараларының1.1.11һәм1.1.12 пункты нигезендә , Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы карары белән расланган шулай ук «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы»Ассоциациясе Президиумы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 1 апрелендәге, 689-р нормерлы боерыгы белән расланган, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе президиумының 2020 елның 9 декабрендәге 187-ПР номерлы карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Кама Тамагы муниципаль районы Советы структурасын раслау турында» 2005 елның 28 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районы Советы структурасын яңа редакциядә (кушымта) расларга.

2. «Кама Тамагы муниципаль районы Советы аппараты структурасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2008 елның 26 июнендәге 185 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карары, «Кама Тамагы муниципаль районы Советы структурасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Кама Тамагы муниципаль районы Советы структурасын раслау хакында» 2005 елның 28 декабрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 29 декабрендәге 34 номерлы карары, «Кама Тамагы муниципаль районы Советы структурасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2013 елның 17 октябрендәге 198 номерлы карары «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2005 елның 28 декабрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3.Әлеге карар имза салынган мизгелдән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Габидуллин Газинур Әүкать улына йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**муниципаль район Советы рәисе** **Н.А.Вазыйхов**

Кама Тамагы муниципаль
районы Советының 2021
елның 29 октябрендәге №
проект карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы Аппараты структурасы**

| **Вазыйфаларның аталышы** | **Кол-во единиц** |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Муниципаль район Башлыгы - муниципаль район Советы рәисе (МР) | 1 |
| Район башлыгы урынбасары, район Советы рәисе урынбасары | 1 |
| МР Советы аппараты җитәкчесе | 1 |
| Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе | 1 |
| Нәтиҗә: | 4 |
| **Оештыру бүлеге:** | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Бүлек башлыгы урынбасары (җирле үзидарә органнары белән эшләү) | 1 |
| Бүлек башлыгы урынбасары (кадрлар эше буенча) | 1 |
| Баш белгеч | 2 |
| Нәтиҗә: | 5 |
| **Юридик бүлек** | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Баш белгеч (тәрҗемәче) | 1 |
| Нәтиҗә: | 2 |
| **Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге** | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| Баш белгеч | 1 |
| Нәтиҗә: | 3 |
| **Гомуми бүлек** | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Баш белгеч | 1 |
| Баш белгеч (секретарь) | 1 |
| 5 разрядлы машина йөртүче | 3 |
| Нәтиҗә: | 6 |
| Барлыгы | 20 |